| ГОСУДАРСТВЕННЫЙ КОМИТЕТ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН ПО ТАРИФАМ | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ ТАРИФЛАР БУЕНЧА ДӘҮЛӘТ КОМИТЕТЫ |
|---|---|---|

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** | **КАРАР**

18.11.2022 Казан ш. № 651-3/г-2022

2023 елга Татарстан Республикасынның торак-коммуналь хуҗалыгын, сәнәгать һәм башка оешмаларын газлаштыру төбәк программасын финанслау өчен «Газпром трансгаз Казан» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыятенең газ бүлү челтәрләре буенча газ транспортлау хезмәте күрсәтүгә тарифларга махсус өстәмә хак күләмен билгеләү турында

«Россия Федерациясендә газ белән тәэмин итү турында» 1999 елның 31 мартындагы 69-ФЗ номерлы федераль закон, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Газлаштыру программаларын финанслау өчен газ бүлүче оешмалар тарафыннан газ транспортлауга тарифларга махсус өстәмәләр билгеләү тәртибе турында» 2001 елның 3 маендагы 335 номерлы, «2022 елның 1 декабреннән 2023 елның 31 декабренә кадәр җайга салынулы бәяләрне (тарифларны) индексацияләү үзенчәлекләре турында һәм Россия Федерациясе Хөкүмәтенең кайбер актларына үзгәрешләр кертү хакында» 2022 елның 14 ноябрендәге 2053 номерлы карарлары, Федераль тарифлар хезмәтенең «Газлаштыру программаларын финанслау өчен газ бүлү оешмалары тарафыннан газ транспортлауга тарифларга махсус өстәмәләр күләмен билгеләү методикасын раслау турында» 2011 елның 21 июнендәге 154-э/4 номерлы боерыгы, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2010 елның 15 июнендәге 468 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты турында нигезләмә, Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты идарәсенең 2022 елның 18 ноябрендәге 39-ПР номерлы утырыш беркетмәсе нигезендә Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасынның торак-коммуналь хуҗалыгын, сәнәгать һәм башка оешмаларын газлаштыру төбәк программасын финанслау өчен «Газпром трансгаз Казан» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыятенең газ бүлү челтәрләре буенча газ транспортлау хезмәте күрсәтүгә тарифларга барлык кулланучы төркемнәре (халыктан тыш) өчен әлеге карар кушымтасына туры китереп махсус өстәмә хак күләмен билгеләргә.

2. Әлеге карарның 1 пунктында билгеләнгән махсус өстәмә күләме 2022 елның

1 декабреннән гамәлгә кертелә.

3. Татарстан Республикасының Тарифлар буенча дәүләт комитетының «2022 елга Татарстан Республикасынның торак-коммуналь хуҗалыгын, сәнәгать һәм башка оешмаларын газлаштыру төбәк программасын финанслау өчен «Газпром трансгаз Казан» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыятенең газ бүлү челтәрләре буенча газ транспортлау хезмәте күрсәтүгә тарифларга махсус өстәмә хак күләмен билгеләү турында» 01.12.2021 № 407-3/г-2021 карарын 2022 елның 1 декабреннән көчен югалткан дип танырга.

4. Әлеге карар 2022 елның 1 декабреннән барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла, дип билгеләргә.

5. Бу карар рәсми басылып чыккан көненнән башлап 10 көн узгач үз көченә керә.

Рәис А.С.Груничев

Татарстан Республикасы Тарифлар
буенча дәүләт комитетының
18.11.2022 № 651-3/г-2022
карарына кушымта

2023 елга Татарстан Республикасынның торак-коммуналь хуҗалыгын,
сәнәгать һәм башка оешмаларын газлаштыру төбәк программасын финанслау өчен
«Газпром трансгаз Казан» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыятенең газ бүлү
челтәрләре буенча газ транспортлау хезмәте күрсәтүгә
тарифларга махсус өстәмә күләме

| Татарстан Республикасының газ бүлү оешмасы исеме | Ел | Махсус өстәмә хак күләме, 1000 куб метр өчен сум (өстәмә хак салымыннан башка) |
|---|---|---|
| «Газпром трансгаз Казан» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте | 01.01.2023 башлап 31.12.2023 кадәр | 211,28 |

Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт
комитетының тариф карарларын кабул итүне
оештыру, контрольдә тоту һәм теркәү бүлеге